КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 17 май г.Казань № 341

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 август, 697 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1018 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль

ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба шул ук эзлеклелектә – чаралар, башка бюджетара трансфертлар) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.»;

4 пунктның икенче абзацында «милекчеләргә» сүзен «хокукка ияләренә» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

дүртенче абзацта «милекчеләргә» сүзен «хокукка ияләренә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«башка бюджетара трансфертлар исәбеннән муниципаль ихтыяҗлар өчен алынырга (базар кыйммәтенә бәйсез бәяләү үткәрелергә) тиешле җир кишәрлекләре, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген;

җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрүгә һәм автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплауга башка бюджетара трансфертлар бирелгән очракта – җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү өчен муниципаль контрактларның расланган күчермәләрен;

җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алуга, шулай ук автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплауга башка бюджетара трансфертлар бирелгән очракта – җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу һәм автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыяннарны каплау турындагы килешүләрнең расланган күчермәләре яки законлы көчкә кергән суд актларының расланган күчермәләрен.»;

8 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгәнбюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.»;

9 пунктта:

алтынчы абзацта «төзүгә» сүзеннән соң «, аларны реконструкцияләүгә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «төзүгә» сүзеннән соң «, аларны реконструкцияләүгә» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «милекчеләргә» сүзен «хокук ияләренә» сүзләренә алмаштырырга, «төзүгә» сүзен «төзүгә, аларны реконструкцияләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алуга һәм автомобиль юллары төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплауга бәйле чыгымнар күләме бәйсез бәяләүгә таянып яки законлы көчкә кергән суд актлары нигезендә билгеләнә.

Бәйсез бәяләүнең заказчысы – җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының кыйммәтенә һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау суммасына йогынты ясый торган бәйсез бәяләү үткәргәндә кулланыла торган документлардагы дөрес булмаган мәгълүмат биргән өчен җаваплы җирле үзидарә органы.»;

16 пунктның беренче абзацында «милекчеләргә» сүзен «хокук ияләренә» сүзләренә алмаштырырга, «төзү максатларында» сүзләрен «төзү, аларны реконструкцияләү максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына Министрлыкка дөрес булмаган мәгълүмат биргән, шул исәптән түбәндәгеләр өчен җаваплылык йөкләнә:

хокук билгели торган гамәлдәге документларга таянып, җир кишәрлекләрен һәм аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында кабул ителгән карарларның нигезлелеге;

заявкадагы мәгълүматларның, шул исәптән бу Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән чыгымнар өлешендә дөрес булмаганы;

җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының кыйммәтенә һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау суммасына йогынты ясый торган бәйсез бәяләү үткәргәндә кулланыла торган документлардагы мәгълүматның дөрес булмаганы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин